Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясе**

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

**буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә (демонстрацион) варианты**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде

**ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының (КҮМ) демонстрация варианты**

**Имтихан эшенең демонстрация вариантына аңлатма**

2016 ел демонстрация варианты белән танышканда шуны күз алдында тотарга кирәк: демонстрация вариантына кертелгән биремнәр 2016 елда КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшерелүче барлык эчтәлек вариантларын чагылдырмый. 2016 ел имтиханында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге www.fipi.ru сайтында урнаштырылган Төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә.

Демонстрация варианты имтиханда катнашучы һәркемгә һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең структурасы, биремнәр саны һәм рәвеше, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру мөмкинлеге бирүгә юнәлтелгән. Бу вариантка кертелгән киңәйтелгән җаваплы биремнәрне үтәүне бәяләүнең монда китерелгән критерийлары киңәйтелгән

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

җавапны язуның тулылыгына һәм дөреслегенә таләпләр турында күзаллау тудырырга мөмкинлек бирә.

Бу мәгълүмат чыгарылыш укучыларына җәмгыять белеме буенча имтихан тапшыруга әзерлекнең стратегиясен эшләү мөмкинлеге тудыра.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



## 2016 ел демонстрация варианты

### Эшне үтәү буенча күрсәтмә

Имтихан эше 31 биремне үз эченә алган ике өлештән тора. 1 өлеш кыска җаваплы 25 биремнән, 2 өлеш киңәйтелгән җаваплы 6 биремнән гыйбарәт.

Җәмгыять белеме буенча имтихан эшен үтәүгә 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

1-20 биремнәргә җаваплар бер сан белән языла, ул дөрес җавап санына туры килә. Бу санны эш текстындагы җавап кырына язып куегыз.

21-25 биремнәргә җаваплар саннар эзлеклелеге рәвешендә эш текстындагы җавап кырында язып куела.

1 өлеш бирeменә дөрес булмаган җавап язган очракта, аны сызыгыз һәм янәшәсендә яңа җавап язып куегыз.

2 өлеш үз эченә текстны һәм аңа 6 биремне (26-31 биремнәр) ала. Әлеге биремнәрне үтәү өчен: тексттан кирәкле мәгълүматны сайлап алырга, аның аерым нигезләмәләрен ачыкларга (шул исәптән мисаллар ярдәмендә); тексттагы мәгълүматларны курс өйрәнү барышында алынган белемнәр белән чагыштырырга; үз фикереңне әйтергә һәм аны нигезләргә. 2 өлештәге биремнәргә җаваплар аерым биттә үтәлә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Биремнәрне үтәгәндә караламадан файдаланырга мөмкин. Караламадагы язмалар эшне бәяләгәндә исәпкә алынмый.

Сезнең тарафтан биремне үтәгәндә алынган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремне үтәргә һәм иң зур сандагы балларны җыярга тырышыгыз.

***Уңышлар телибез!***

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



## 1 өлеш

**1-20 биремнәрне үтәгәндә җавап кырында дөрес җавапка туры килүче бер сан языгыз**

**1** Җәмгыятьнең сәяси өлкәсен сурәтләнгәндә санап кителгән терминнарның кайсысы беренче чиратта кулланыла?

1) кабиләләр, халыклар
2) катламнар, сыйныфлар
3) республика, федерация
4) чыгымнар, керемнәр

Җавап:

**2** Китерелгән мисалларның кайсысы шәхесара аралашуны сурәтли?

1) Дәүләт башлыгы массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарга мөрәҗәгать итә.
2) Табиблар сәламәтлек саклау министры докладын тыңлый.
3) Дуслар ачуланышканнан соң очраштылар, ачуланышуның сәбәбен ачыкладылар һәм дуслаштылар.
4) Һөнәр берлекләре митинг оештыру турында фикер алыштылар

Җавап:

**3** Укучылар дәрестә бер гаиләнең аерылышуы турындагы мисал нигезендә РФнең гаилә турында законнарын

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

өйрәнделәр. Әлеге уку эшчәнлеге субъекты булып тора:
1) гаилә турында законнар
2) дәрес
3) укучылар
4) гаилә пары

Җавап:

**4** Җәмгыять турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Җәмгыять табигатьнең бер өлеше булып тора.
Б. Җәмгыять структурасына иҗтимагый тормыш өлкәләре керә.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

Җавап:

**5** Гимназиянең унынчы сыйныф укучысы Виолетта актерлык осталыгы буенча абруйлы балалар конкурсында җиңү яулады. Ул шулай ук балалар вокал студиясендә шөгыльләнә. Виолетта нинди уку баскычында тора?
1) гомуми башлангыч белем
2) төп гомуми белем
3) төп урта белем
4) урта һөнәри белем

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Җавап:

**6** Хәзерге заманда фәннең роле турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Фән кешегә әйләнә-тирә дөнья турында белемнәрне системага салырга ярдәм итә.
Б. Фән ирешкән нәтиҗәләрнең дөрес булуына омтыла.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

Җавап:

**7** Санап кителгәннәрнең кайсылары җитештерү факторлары (ресурслары) булып тора?
1) керем 2) хезмәт 3) салымнар 4) хезмәт хакы

Җавап:

**8** Кешеләрнең законнар кысаларында тәвәккәл, керем алуга юнәлтелгән инициативалы мөстәкыйль хуҗалык эшчәнлеге түбәндәгечә атала
1) эшкуарлык
2) реформалау
3) җитештерү
4) иҗат

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җавап: ☐

**9** Z дәүләтендә товар җитештерү һәм акча әйләнеше бар. Нинди өстәмә мәгълүмат Z дәүләтенең икътисады базар икътисады дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә?

1) Дәүләт хезмәткәрләргә хезмәт хакы күләмен билгели
2) Финанс министрлыгы алынган керемне ничек файдалану мәсьәләсен хәл итә
3) Балигъ булмаган хезмәткәрләргә ташламалы хезмәт шартлары тәкъдим ителә
4) Җитештерүче нәрсә һәм күпме җитештерәсен үзе билгели

Җавап: ☐

**10** Ресурсларның чикле булуы турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Ресурсларның чикле булуы мәсьәләсе заманча фән тарафыннан тулысынча хәл ителергә мөмкин.

Б. Ресурсларның чиклелеге җәмгыятьнең ихтыяҗлары үсү белән бәйле.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



**11** Җәмгыять структурасы социаль берлекләр һәм төркемнәр җыелмасы буларак бирелгән. Кайсы социаль төркем территориаль билгесе буенча аерып күрсәтелгән?

1) крестьяннар 2) рязаньлылар 3) руслар 4) пассажирлар

Җавап: ☐

**12** Яшүсмерләр дә, шул ук вакытта олы яшьтәге кешеләр дә нинди социаль роль уйный ала?

1) куллanучы
2) сайлаучы
3) урта мәктәптә укучы
4) автомобиль йөртүче

Җавап: ☐

**13** Социаль каршылык турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Социаль каршылык гел тискәре нәтиҗәләргә китерә.

Б. Социаль каршылык формасы һәм үсеш характеры буенча аерыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**14** Дәүләт хакимиятен тормышка ашыра:
1) университет ректоры
2) хөкүмәт рәисе
3) оппозициядә булган партия лидеры
4) үзәк банк рәисе

Җавап: ☐

**15** Z дәүләтендә югары хакимият идарәчегә мирас буенча тапшырыла. Ул министрлар кабинеты эшчәнлеге белән идарә итә, законнар кабул итә, суд карарларын раслый. Z дәүләтендә нинди идарә формасы гамәлдә?
1) федерация
2) абсолют монархия
3) унитар дәүләт
4) республика

Җавап: ☐

**16** Сәяси партияләр турында түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Сәяси партия хакимиятне тормышка ашыруда катнашырга омтыла.
Б. Сәяси партия билгеле бер социаль көчләр мәнфәгатьләрен чагылдыручы бердәй карашлы кешеләр төркемен берләштерә.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Җавап: ☐

**17** Хокукый нормалар, башка социаль нормалардан аермалы буларак,
1) дәүләт көченә таяна
2) кешеләрнең үз-үзен тотышын җайга сала
3) иҗтимагый фикергә таяна
4) үз-үзеңне ничек тоту үрнәкләрен үз эченә ала

Җавап: ☐

**18** РФ Конституциясе нигезендә РФ Хөкүмәте
1) законнар кабул итә
2) хокукый дәгъваларны хәл итә
3) РФ субъектлары арасында чикләр үзгәрүне раслый
4) федераль милек белән идарә итүне тормышка ашыра

Җавап: ☐

**19** Гражданин К. улына туган көненә үз машинасын бүләк итә. Әлеге мисал, беренче чиратта, К.ның үз милкенә карата нинди хокукта булуын раслый.
1) ия булу
2) эш итү
3) файдалану
4) мирас итеп бирү

Җавап: ☐

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**20** Дәүләтнең хокук саклау органнары турында түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан законнар үтәлешенә күзәтчелекне адвокатура тормышка ашыра.

Б. Полиция бурычларына шәхеснең куркынычсызлыгын тәэмин итү керә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике фикер дә дөрес
4) Ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**21-25 биремнәргә саннар эзлеклелеге җавап булып тора. Әлеге саннар эзлеклелеген эш текстында җавап кырында языгыз.**

**21** Z дәүләтендә демократик сәяси режим урнаштырылган, ә Y дәүләтендә – тоталитар. Әлеге ике сәяси режимны чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш яклар күрсәтелгән тәртип санын, ә икенче баганага аерымлыклар күрсәтелгән тәртип санын сайлап алып языгыз.

1) җәмгать тәртибен бозуны булдырмау
2) башкарма хакимият органнары булу
3) альтернатив нигездә ирекле сайлаулар
4) судтан тыш органнар тарафыннан хөкем чыгару

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Җавап:

| Охшаш яклар | | Аерымлыклар | |
|---|---|---|---|
| | | | |

**22** Кеше хокуклары (ирекләре) һәм үзләре карый торган хокуклар (ирекләр) төркеме арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны сайлап алыгыз.

| КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ (ИРЕКЛӘРЕ) | ХОКУКЛАР (ИРЕКЛӘР) ТӨРКЕМЕ |
|---|---|
| А) сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәме алуга хокук | 1) гражданлык (шәхси) |
| Б) нигезсез рәвештә шәхси тормышка тыкшынудан яклау | 2) сәяси |
| В) намус һәм абруйны яклауга хокук | 3) социаль |
| Г) тынычлыкка нигезләнгән җыелышларга һәм ассоциацияләргә ирек хокукы | |
| Д) яшәргә хокук | |

Таблицага тиешле хәрефләр астына сайлап алынган саннарны языгыз.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Җавап:


| А | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**Текстны укып чыгыгыз. Статистик мәгълүматларны анализлагыз һәм 23, 24 биремнәрне үтәгез.**

Z дәүләтендә җәмәгатьчелек фикерен сораштыру уздырылды. Сораштыруда катнашучы гражданнарга түбәндәге сорау бирелде: “Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның кайсы ысулын Сез аеруча нәтиҗәле дип саныйсыз?”
Сораштыру нәтиҗәләре (сораштырылучылар саныннан процентларда) диаграмма рәвешендә бирелгән.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте






**23** Түбәндә китерелгән исемлектән диаграмма нигезендә ясалырга мөмкин булган нәтиҗәләрне табыгыз һәм алар урнаштырылган саннарны языгыз.

1) Хезмәт хакын арттыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның нәтиҗәле ысулы дип санаучылар саны шәхси предприятие хезмәткәрләренә караганда дәүләт предприятиеләре хезмәткәрләре арасында күбрәк.
2) Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның нәтиҗәле ысулы буларак җитештерүне модернизацияләүнең әһәмияте дәүләт предприятиеләре хезмәткәрләренә караганда шәхси предприятие хезмәткәрләре өчен кимрәк.
3) Кадрларның квалификацияләрен күтәрү хезмәт

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

җитештерүчәнлеген арттыруның нәтиҗәле ысулы дип санаучылар саны шәхси предприятие хезмәткәрләренә караганда дәүләт предприятиеләре хезмәткәрләре арасында күбрәк.

4) Шәхси фирмалар хезмәткәрләренең тигез өлеше хезмәткәрләрнең квалификацияләрен күтәрү һәм яхшы хезмәт шартлары булдыруны хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның нәтиҗәле ысуллары дип билгеләде.

5) Хезмәт хакын арттыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның нәтиҗәле ысулы дигән фикер ике төр предприятиеләр хезмәткәрләре арасында да киң таралган.

Җавап: ______

**24** Диаграммада сурәтләгән сораштыру нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылды һәм аларга комментарийлар бирелде. Түбәндә китерелгән нәтиҗәләрнең кайсысы турыдан-туры сораштыру барышында алынган мәгълүматтан килеп чыга? Алар күрсәтелгән саннарны языгыз.

1) Хезмәткәрләрнең күбесе хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны фәнни-техник алгарыш белән бәйли.

2) Квалификацияне күтәрү мәсьәләсе шәхси фирмалар хезмәткәрләре һәм шулай ук дәүләт предприятиеләре хезмәткәрләре өчен бер үк дәрәҗәдә актуаль түгел.

3) Җитештерүне модернизацияләү хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



4) Сораштырылучыларның шактый өлеше өчен матди кызыксындыру чаралары әйдәүче урынны алып тора.

5) Фирманың уңышлы эшләве аның техник яктан җиһазландырылу дәрәҗәсенә бәйле.

Җавап: ______

**25** Түбәндә китерелгән текстны укыгыз, аның һәр җөмләсе аерым хәреф белән билгеләнгән.

(А) Мария институтны тәмамлады һәм бухгалтер булып эшли. (Б) Ул һөнәри әдәбиятны укый, законнардагы үзгәрешләрне карап бара. (В) Мария дөрес эшли: хезмәткәргә һөнәри өлкәдә конкурентлылыкка сәләтле булыр өчен үзенең белемен арттыру өстендә эшләргә кирәк.

Текстның кайсы җөмләләре нәрсәне билгеле икәнен ачыклагыз:

1) Фактларны гәүдәләндерә
2) Фикерләрне чагылдыра

Таблицага тиешле җөмләләрнең характерын күрсәтүче саннарны языгыз.

Җавап:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

## 2 өлеш

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

***Әлеге өлештәге биремнәргә (26-31) җавап бирү өчен аерым кәгазь бите кулланыгыз. Беренче бирем номерын (26, 27 һ.б.), аннары аңа киңәйтелгән җавапны языгыз. Җавапларны төгәл һәм аңлашылырлык итеп языгыз.***

***Текстны укыгыз һәм 26-31 биремнәрне үтәгез.***

Без мәгариф, белемнәр, һөнәри тәҗрибә кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Һаман саен катлаулана барган белемнәрсез эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлаячак. Ә моның өчен кешенең гомуми зыялылыгы, аның һаман яңа әйберләр булдыру сәләте һәм, әлбәттә, машинада берничек тә булмаган әхлакый җаваплылыгы кирәк булачак, кешегә гади кеше генә түгел, ә фән кешесе булу, машиналар һәм роботлар гасырында барган барлык нәрсәләр өчен әхлакый яктан җавап бирүче кеше булу кебек бик авыр һәм бик катлаулы җаваплылык төшә. Гомуми белемнәр киләчәк кешесен, иҗади кешене, барлык яңалыкны бар итүче, булдыручы, һәр нәрсә өчен җавап бирүче кешене тәрбияли ала.

Уку – яшь кешегә кече яшьтән үк хәзер менә шул кирәк. Һәрвакыт укырга кирәк. Барлык зур галимнәр гомер ахырына кадәр үзләре өйрәтеп кенә калмадылар, үзләре дә укыдылар. Өйрәнүдән туктасаң – укыта да алмыйсың. Чөнки белемнәр һаман арта һәм катлаулана бара. Шул ук вакытта шуны истә тоту зарур, уку өчен иң кулай вакыт – яшьлек. Нәкъ менә яшьлектә, бала чакта, яшүсмер вакытта кешенең акылы бар нәрсәне яхшырак кабул итә.

Вакытыгызны юк-барга, “ял итүгә” әрәм-шәрәм итмәгез, алар кайчакта иң авыр эштән дә күбрәк ялыктыра, үзегезнең саф акылыгызны ахмак һәм максатсыз “мәгълүматның” болганчык ташкыны белән тутырмагыз. Үзегезне уку, белемнәр һәм тәҗрибә алу өчен саклагыз, аларны сез яшь чагында гына җиңел һәм тиз үзләштерә аласыз.

Менә монда инде мин яшь кешенең авыр сулап куюын ишетәм: безнең яшьләргә сез нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез! Һаман укырга гынамы? Ә ял, күңел ачулар кайда? Нәрсә, инде безгә шатланырга да ярамыйммы?

Һич тә алай түгел. Тәҗрибә һәм белем алу – шул ук спорт ул. Аннан тәм таба белмәсәң, уку авыр ул. Укуны яратырга, ә ял һәм күңел ачуның акыллысын, нәрсәгә дә булса өйрәтә, үзегездә нинди дә булса сәләтне үстерә алырлыгын сайлый белергә кирәк, алар тормышта кирәк булачак әле...

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Укуны яратырга өйрәнегез!

*(Д.С. Лихачёв)*

**26** Текст планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви өзекләрен билгеләгез һәм аларга исемнәр бирегез.

**27** Автор фикере буенча XXI гасырда җитештерүдә кешенең роле нинди булачак? Автор фикере буенча кешегә кирәк булачак ике сыйфатны күрсәтегез.

**28** Автор фикере буенча ни өчен яшь кешегә кечкенә вакытыннан ук укырга кирәк? Текстны кулланып, ике сәбәбен күрсәтегез.

**29** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу формаларын тәкъдим итә. Шундый формаларга ике мисал китерегез; һәрберсендә әлеге форманың нинди сыйфатларны үстерүен күрсәтегез.

**30** Автор кешенең “машиналар һәм роботлар

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



гасырында барган барлык нәрсәләр” өчен әхлакый яктан җаваплылыгы турында яза. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән файдаланып, әлеге фикергә ике аңлатма бирегез.

**31** Автор “һәрвакыт укырга кирәк” дип саный. Текстны һәм җәмгыять белемен кулланып, ике дәлил (аңлатма) белән кешенең бөтен гомере буена өзлексез белем алу зарурлыгын раслагыз.

## Җәмгыять белеме буенча имтихан эшен бәяләү системасы

### 1 өлеш

1 өлештәге биремнәргә һәр дөрес җавап өчен, 22 биремнән кала, 1 балл бирелә. 22 бирем түбәндәге принцип буенча бәяләнә: 2 балл – хаталар булмаса; 1 балл – бер хата булса; 0 балл – ике яисә аннан да күбрәк хата булганда.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| Бирем номеры | Җавап |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 3 |
| 3 | 3 |
| 4 | 2 |
| 5 | 3 |
| 6 | 3 |
| 7 | 2 |
| 8 | 1 |
| 9 | 4 |
| 10 | 2 |
| 11 | 2 |
| 12 | 1 |
| 13 | 2 |
| 14 | 2 |
| 15 | 2 |
| 16 | 3 |
| 17 | 1 |
| 18 | 4 |
| 19 | 2 |
| 20 | 2 |
| 21 | 1234 |
| 22 | 31121 |
| 23 | 145 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| 24 | 24 |
| 25 | 112 |

**2 өлеш**

**Киңәйтелгән җаваплы биремнәрне бәяләү критерийлары**

Без мәгариф, белемнәр, һөнәри тәҗрибә кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Һаман саен катлаулана барган белемнәрсез эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлаячак. Ә моның өчен кешенең гомуми зыялылыгы, аның һаман яңа әйберләр булдыру сәләте һәм, әлбәттә, машинада берничек тә булмаган әхлакый җаваплылыгы кирәк булачак, кешегә гади кеше генә түгел, ә фән кешесе булу, машиналар һәм роботлар гасырында барган барлык нәрсәләр өчен әхлакый яктан җавап бирүче кеше булу кебек бик авыр һәм бик катлаулы җаваплылык төшә. Гомуми белемнәр киләчәк кешесен, иҗади кешене, барлык яңалыкны бар итүче, булдыручы, һәр нәрсә өчен җавап бирүче кешене тәрбияли ала.

Уку – яшь кешегә кече яшьтән үк хәзер менә шул кирәк. Һәрвакыт укырга кирәк. Барлык зур галимнәр

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

гомер ахырына кадәр үзләре өйрәтеп кенә калмадылар, үзләре дә укыдылар. Өйрәнүдән туктасаң – укыта да алмыйсың. Чөнки белемнәр һаман арта һәм катлаулана бара. Шул ук вакытта шуны истә тоту зарур, уку өчен иң кулай вакыт – яшьлек. Нәкъ менә яшьлектә, бала чакта, яшүсмер вакытта кешенең акылы бар нәрсәне яхшырак кабул итә.

Вакытыгызны юк-барга, "ял итүгә" әрәм-шәрәм итмәгез, алар кайчакта иң авыр эштән дә күбрәк ялыктыра, үзегезнең саф акылыгызны ахмак һәм максатсыз "мәгълүматның" болганчык ташкыны белән тутырмагыз. Үзегезне уку, белемнәр һәм тәҗрибә алу өчен саклагыз, аларны сез яшь чагында гына җиңел һәм тиз үзләштерә аласыз.

Менә монда инде мин яшь кешенең авыр сулап куюын ишетәм: безнең яшьләргә сез нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез! Һаман укырга гынамы? Ә ял, күңел ачулар кайда? Нәрсә, инде безгә шатланырга да ярамыймы?

Һич тә алай түгел. Тәҗрибә һәм белем алу – шул ук спорт ул. Аннан тәм таба белмәсәң, уку авыр ул. Укуны яратырга, ә ял һәм күңел ачуның акыллысын, нәрсәгә дә булса өйрәтә, үзегездә нинди дә булса сәләтне үстерә алырлыгын сайлый белергә кирәк, алар тормышта кирәк булачак әле...

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Укуны яратырга өйрәнегез!

*(Д.С. Лихачёв)*

**26** Текст планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви өзекләрен билгеләгез һәм аларга исемнәр бирегез.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта план пунктлары текстның төп мәгънәви өзекләренә туры килергә һәм аларның һәркайсының <u>төп идеясен чагылдырырга</u> тиеш.<br>Түбәндәге <u>мәгънәви өзекләр</u> аерып күрсәтелергә мөмкин:<br>1) XXI гасырда мәгарифнең роле;<br>2) кешенең фән алдында әхлакый җаваплылыгы;<br>3) яшьлек чоры – уку вакыты;<br>4) укудан шатлык табарга өйрәнү.<br>План пунктларын өзекнең төп идеясе эчтәлегенә хилафлык китермәслек итеп башка төрле формалаштырырга да мөмкин. | |
| Текстның төп мәгънәви өзекләре | 2 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| күрсәтелгән, аларның исемнәре (план пунктлары) текстның һәрбер өзегенең төп идеясен чагылдыра.<br>Күрсәтелгән өзекләр саны төрле булырга мөмкин | |
| Текстның мәгънәви өзекләре яртысыннан артыгы дөрес күрсәтелгән, аларның исемнәре (план пунктлары) текстның тиешле өзегенең төп идеясен чагылдыра.<br>ЯИСӘ текстның төп мәгънәви өзекләре күрсәтелгән, ләкин барлык исемнәр (план пунктлары) текстның һәрбер өзегенең төп идеясен чагылдырмый. | 1 |
| Текстның төп өзекләре күрсәтелмәгән.<br>ЯИСӘ күрсәтелгән өзекләрнең исемнәре (план пунктлары) текстның тиешле өлешләренең төп идеясенә туры килми, алар тиешле өзектән цитаталар булып тора.<br>ЯИСӘ җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**27** Автор фикере буенча XXI гасырда җитештерүдә кешенең роле нинди булачак? Автор фикере буенча кешегә кирәк булачак ике сыйфатны күрсәтегез.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>*(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавап түбәндәге <u>элементлардан</u> торырга тиеш:<br>1) роль: кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлый алачак;<br>2) сыйфат: кешенең гомуми зәвыгы, аның яңа әйберләр уйлап таба алу сәләте, әхлакый җаваплылыгы.<br>Җавап элементлары мәгънәсе ягыннан якын булган башка формулировкаларда бирелергә мөмкин. | |
| Роль һәм ике сыйфаты дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бары тик роль генә дөрес күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Роль һәм бер сыйфаты дөрес күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Бары тик ике сыйфаты дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Бары тик бер сыйфаты гына дөрес күрсәтелгән<br>ЯИСӘ җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

**28** Ни өчен автор фикере буенча яшь кешегә кечкенә вакытыннан ук укырга кирәк? Текстны файдаланып, ике сәбәбен күрсәтегез.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге <u>сәбәпләр</u> күрсәтелергә мөмкин:<br>1) белемнәр арта һәм катлаулана;<br>2) нәкъ менә яшь чакта кеше аңы аеруча нык сеңдерә.<br>Җавап элементлары мәгънәсе ягыннан якын булган башка формулировкаларда бирелергә мөмкин. | |
| Ике сәбәп дөрес күрсәтелгән | 2 |
| Бер сәбәп дөрес күрсәтелгән | 1 |
| Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**29** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу формаларын тәкъдим итә. Шундый формаларга ике мисал китерегез; һәрберсендә әлеге форманың нинди сыйфатларны үстерүен күрсәтегез.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге <u>элементлар</u> күрсәтелергә тиеш:<br>1) сорауга җавап: автор ял итүнең, күңел ачуның тормышта кирәк булачак, безне нәрсәгә дә булса өйрәтә алачак, бездә сәләтләр үстерергә ярдәм итүче “акыллы” формаларын тәкъдим итә.<br>2) <u>сыйфатларны күрсәтеп, ике мисал</u>, мәсәлән:<br>- спорт секциясендә шөгыльләнү көчле, җитез булырга, ихтыяр көчен үстерергә, партнерлар һәм көндәшләр белән аралашырга булыша;<br>- әдәби әсәрләр уку фикерләүне, хисләрне уртаклашуны үстерә; дөнья һәм кеше турында күзаллауны киңәйтә.<br>Җавап элементлары мәгънәсе ягыннан якын булган башка формулировкаларда бирелергә мөмкин. | |
| Сорауга җавап бирелгән, ике мисал китерелгән, икесендә дә сыйфатлар | 3 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| күрсәтелгән | |
| Сорауга җавап бирелгән, бер-ике мисал китерелгән, сыйфатлар бары тик бер форма өчен генә күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Сорауга җавап бирелгән, бер мисал китерелгән, сыйфатлар ике форма өчен күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Ике мисал китерелгән, һәрбер очракта сыйфатлар күрсәтелгән. | 1 |
| Сорауга җавап бирелгән, ике мисал китерелгән.<br>ЯИСӘ Сорауга җавап бирелгән һәм сыйфат күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Ике мисал китерелгән.<br>ЯИСӘ Бары тик ике сыйфат кына күрсәтелгән.<br>ЯИСӘ Бары тик сорауга җавап кына бирелгән. | 0 |
| *Максималь балл* | *3* |

**30** Автор кешенең “машиналар һәм роботлар гасырында барган барлык нәрсәләр” өчен әхлакый яктан җаваплылыгы турында яза. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән файдаланып, әлеге фикергә ике аңлатма бирегез.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>*(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге аңлатмалар бирелергә мөмкин:<br>Кеше “машиналар һәм роботлар гасырында барган барлык нәрсәләр” өчен әхлакый яктан җаваплы, чөнки:<br>1) XX гасырның икенче яртысында кешелек очрашкан глобаль икътисадый проблемалар кешеләрнең интенсив рәвештә алып барган үзгәртеп кору эшчәнлеге белән бәйле, аның характеры һәм юнәлеше XXI гасырда да үзгәрмәде;<br>2) үсеп килүче техника һәм технология җәмгыять үсешенә уңай тәэсир итү белән бергә, алар кешелек яшәешенә потенциаль куркыныч булып тора.<br>Башка төрле аңлатмалар бирелергә мөмкин. | |
| Ике аңлатма бирелгән | 2 |
| Бер аңлатма бирелгән | 1 |
| Бирем таләбенә туры килмәүче гомуми характердагы фикерләр китерелә.<br>ЯИСӘ җавап дөрес түгел | 0 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | |
|---|---|
| *Максималь балл* | *2* |

| | |
|---|---|
| **31** | Автор “һәрвакыт укырга кирәк” дип саный. Текстны һәм җәмгыять белемен кулланып, ике дәлил (аңлатма) белән кешенең бөтен гомере буена өзлексез белем алу зарурлыгын раслагыз. |

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** *(җавапның, аның мәгънәсен бозмаучы башка формулировкалары да рөхсәт ителә)* | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге дәлилләр (аңлатмалар) бирелергә мөмкин:<br>1) хәзерге заманда белемнәр бик тиз искерә, шуңа күрә аларны гел тулыландырып, төзәтмәләр кертеп торырга кирәк;<br>2) хәзерге заман кешеләре еш кына эшен алыштыра, шуңа да аларга яңа мәгълүмат һәм эшчәнлек төрләре үзләштерергә туры килә.<br>Башка төрле аңлатмалар бирелергә мөмкин. | |
| Ике дәлил (аңлатма) китерелгән | 2 |
| Бер дәлил (аңлатма) китерелгән | 1 |
| Бирем таләбенә туры килмәүче гомуми характердагы фикерләр китерелә. | 0 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



| | |
|---|---|
| ЯИСӘ җавап дөрес түгел | |
| *Максималь балл* | *2* |

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациялəве үткәрү тәртибе (Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

26-31 биремнәрнең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар аермасы 2 һәм аннан күбрәк булса, *өченче эксперт шундый җитди аермага китергән биремнәрне генә тикшерә.*



© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте